**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чемодурово авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чемодурово авылы № 112 «12» октябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 ноябрендәге 72 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак вакыт нигездә файдалануга бирү өчен өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибенең 1.7 пунктының үз көчен югалтуын тану турында

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасы нигезендә

Чемодурово авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 ноябрендәге 72 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак вакыт нигездә файдалануга бирү өчен өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибенең 1.7 пунктының үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Башлык Н.Б.Котельникова